# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 5 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

"Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында" 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 3 пунктындагы унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"оешма ябылуга йә физик затларның индивидуаль эшкуарлар буларак эшчәнлекләре туктауга бәйле рәвештә эштән азат ителгән, бала туугa һәм аны карауга бәйле рәвештә эшендә өзеклек булган хатын-кызлар;";

2) 3 статьяда:

а) 2 өлешнең 1 пунктын көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

"$4^1$. Федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә вазыйфага сайлап кую, тиешле вазыйфаны биләүгә конкурс буенча сайлап алу, вазыйфага билгеләнү яисә вазыйфага раслану юлы белән биләнә торган вазыйфалар дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар хезмәткәрләренең исемлектәге уртача санына керми.";

3) 4 статьяның 1 өлешендә "оешмалардан тыш, оешмаларда" сүзләрен "оешмалардан тыш, эш бирүчеләрдә" сүзләренә алмаштырырга;

4) 5 статьяда:

а) 1 өлештә "оешмаларда" сүзен "эш бирүчеләрдә" сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә "оешмаларга" сүзен "эш бирүчеләргә" сүзләренә, "оешма хезмәткәрләренең" сүзләрен "эш бирүче хезмәткәрләренең" сүзләренә алмаштырырга;

5) 6 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында "башка оешмаларда" сүзләрен "башка эш бирүчеләрдә" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 20 июле
№ 59-ТРЗ